**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР**
**25.02.2019**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 332**

**Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны теркәү һәм исәпкә алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

“Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгының 2015 ел, 10 нчы март, 1389/15 номерлы боерыгы белән расланган “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны теркәү һәм исәпкә алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең якынча Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында” Татарстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгының 2018 ел, 26 нчы декабрь под-1975/18 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районыны Башкарма комитетының 2018 ел, 29 нчы гыйнвар 278 номерлы карары белән расланган (2018 ел, 16 нчы июль 1536 номерлы карары редакциясендә) «Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны теркәү һәм исәпкә алу» муниципаль хезмәт күрсәтүнең Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 нче пунктта:

1) 3.4.4. подпунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

“Билгеләнгән ташлама срогы чыккач, Гариза бирүчегә үзенең Оешмага чираттан тыш яки беренче чиратта теркәлү хокукын расларга кирәк була.”

2) 3.4.6. подпунктының өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Уку елы дәвамында буш урыннар булган очракта, Оешмаларда әлеге Административ регламентның 3 пунктында каралган тәртиптә кабаттан комплектланып бетерелү уздырыла.”

3) 3.4.6. подпунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

4) 3.4.6. подпунктының алтынчы абзацындагы “5 эш көненнән дә артмаган” сүзләрен “бер эш көненнән дә артмаган” сүзләре белән алмаштырырга;

5) 3.5.2. подпунктының өченче абзацындагы “3 ай дәвамында” сүзләрен “Бер ай дәвамында” сүзләре белән алмаштырырга;

6) 3.5.4. подпунктының беренче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

“Теркәлергә теләгән дата Гариза бирүченең юлламадан баш тартуы турында мөрәҗәгать иткән көненнән алда булмаган датага алыштырыла.”;

7) 3.5.5. подпунктының беренче абзацында “Оешма җитәкчесе Системада гаризага «Килмәде» дигән статус бирә” сүзләрен “Гаризага Системада «Килмәде» статусы бирелә” дигән сүзләр белән алмаштырырга;

8) 3.5.6. пунктының беренче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

“Расланган очракта теркәлергә теләгән дата Гариза бирүченең муниципаль хезмәт алуда ихтыяҗ булуын раслап мөрәҗәгать иткән көненнән алда булмаган датага алыштырыла.”;

9) 3.6.2. пунктының икенче абзацындагы “3 ай вакыт узгач” сүзләрен “бер ай вакыт узгач” сүзләре белән алмаштырырга;

10) 3.6.3. пунктының беренче абзацын түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга:

“Расланган очракта теркәлергә теләгән дата Гариза бирүченең муниципаль хезмәт алуда ихтыяҗ булуын раслап мөрәҗәгать иткән көненнән алда булмаган датага алыштырыла”.

1.2. 5 нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Гариза бирүченең Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затының, яки муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә күздә тотылган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе.

5.1. Муниципаль хезмәтне алучылар муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы мәгариф бүлеге хезмәткәрләренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан тыш) мәгариф бүлеге җитәкчесенә, ә мәгариф бүлеге җитәкчесе карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) Башкарма комитетка шикаять белдерү хокукына ия.

Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) закон белән билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелә.

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин:

1) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән соратуның, муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратуның теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 2010 ел, 27 нче июль, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

3) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларында каралмаган өстәмә документлар һәм мәгълүматлар яисә эшчәнлекне тормышка ашыруны таләп итү;

4) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итүне кире кагу;

5) федераль законнар, алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актларында кире кагу өчен җирлек булмаган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 2010 ел, 27 нче июль, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә билгеле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткән вакытта Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә күздә тотылган оешмаларның, яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә документларда алар җибәргән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тарту, яисә андый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозган очракта. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә билгеле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирүнең срогын һәм тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору, әгәр дә федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка төр норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка төр норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актларында моның өчен нигез булмаса. Күрсәтелгән

очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә билгеле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин.

10) муниципаль хезмәт күрсәткән вакытта гариза бирүчедән беренче тапкыр документларны кабул иткәндә кире каккан вакытта булмаган һәм (яки) күрсәтелмәгән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм мәгълүматларны таләп итү, яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пунктында каралган очраклардан кала муниципаль хезмәт күрсәтү. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә билгеле муниципаль хезмәт күрсәтү тулы күләмдә һәм тәртиптә булган очракта гына мөмкин;

5.3. Муниципаль хезмәтне алучы шикаятьне карау һәм нигезләү өчен кирәкле булган мәгълүмат һәм документларны алырга хокуклы.

5.4. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада җибәрелә.

Шикаять почта, күпфункцияле үзәк, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрен кулланып, Биектау муниципаль районы рәсми сайты (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы буенча, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерү почта, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрен кулланып, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайты, Татарстан Республикасы бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы буенча, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы “г” бүлегендә каралган оешмалар һәм (яки) аларның хезмәткәрләре карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерү почта, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрен кулланып, әлеге оешмаларның рәсми сайтлары, Татарстан Республикасы бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы буенча, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.5. Шикаятьне карау срогы – аны теркәгән көннән башлап унбиш эш көне дәвамында. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органның вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән яки әлеге төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозу буенча шикаятьтән баш тартса - теркәлгән көннән башлап биш эш көне дәвамында.

5.6. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелүче муниципаль хезмәт күрсәтү органы, муниципаль хезмәт күрсәтү органы вазыйфаи затының, яки дәүләт һәм муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) аларның хезмәткәрләренең исемнәре;

2) гариза бирүчегә җавап бирү өчен фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (соңгысы булган очракта), гариза бирүченең яшәү урыны турында белешмә – физик затның яисә исеме, юридик затның урнашкан урыны турында белешмә, хәбәрләшү өчен телефон номеры, электрон почта адресы (адреслары) (ахыргысы булган очракта) һәм почта адресы;

3) карарларына һәм эшчәнлекләренә (гамьсезлекләренә) шикаять белдерелүче муниципаль хезмәт күрсәтү органы, муниципаль хезмәт күрсәтү органы вазыйфаи заты, яки дәүләт һәм муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1.1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) аларның хезмәткәрләре турында мәгълүматлар;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү органы, муниципаль хезмәт күрсәтү органы вазыйфаи заты, яки дәүләт һәм муниципаль хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмалар, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм эшчәнлекләре (гамьсезлекләре) дәлилләре белән килешмәү нигезләре.

5.7. Гариза бирүче дәлилләрне раслаучы документлар һәм аларның күчермәсен тәкъдим итә ала (булган очракта).

5.8. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны кире кагу формасында, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән гаризаны кертү вакытында җибәрелгән хәреф хаталарын һәм хаталарны төзәтү буенча төзәтмәләрне, гариза бирүчегә акчалата чараларны кире кайтару, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә акча алу каралмаган;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән тәртиптә, карар кабул ителгән көннән соң, икенче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә, гариза бирүченең теләге булган очракта электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап хаты җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылган очракта, гариза бирүчегә җавапта муниципаль хезмәт күрсәтү органының, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 1 бүлегендә каралган оешмаларның тормышка ашыра торган эшчәнлекләре турында, муниципаль хезмәт күрсәткән вакытта ачыкланган кагыйдә бозуларны кичекмәстән бетерү максатыннан мәгълүмат бирелә, шулай ук гариза бирүчегә муниципаль хезмәтне алу максатыннан эшләргә

кирәкле эшчәнлек турында мәгълүмат күрсәтелә һәм китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу сорала.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карар турында дәлилләр белән аңлатмалы җавап, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.11. Карарны кабул итү барышында һәм шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки вазыйфаи зат тарафыннан хокук бозу очраклары булу мөмкинлеге ачыкланса, шикаятьятләрне карау буенча вәкаләтләргә ия булган хезмәткәр барлык материалларны прокуратура органнарына җибәрә.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 ел, 16 нчы июль 1536 номерлы карары белән расланган “Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 ел, 29 нчы гыйнвар 278 номерлы “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) тормышка ашыручы белем бирү оешмаларына балаларны теркәү һәм исәпкә алу” муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында” карарының 1 пункты 1.4. подпунктын төшереп калдырырга.

3. Әлеге карарны “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресында урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары - Биектау муниципаль районы мәгариф бүлеге начальнигы Әхмәтҗанов Н.К.га йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин